ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 584-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.А. Чубаров тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 584-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 11 июле
№ 2592-VI ДС

проект

**«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 27 июнендәге 42 номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 51 (I өлеш), «$1^1$ өлеше» сүзләрен «$2^1$ өлеше» сүзләренә алмаштырып, «Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең эшчәнлеген камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 6 апрелендәге 76-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр турында» 2020 елның 18 мартындагы 48-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләренә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 27 июнендәге 42 номерлы Татарстан Республикасы Законында Татарстан Республикасында бер үк кешенең кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасын биләп тору срокларын билгеләгәндә «Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең эшчәнлеген камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 6 апрелендәге 76-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр башланган вазыйфаны биләп тору сроклары исәпкә алынмый.

Әлеге Федераль закон белән «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелде – ул Россия Федерациясе субъектларында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең эшчәнлеген җайга сала торган $16^1$ статья белән тулыландырылды.

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның $16^1$ статьясы, шулай ук «Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең эшчәнлеген камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 6 апрелендәге 76-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2022 елның 1 июненнән үз көчен югалткан дип танылды.

2020 елның 29 мартында «Россия Федерациясе субъектларында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр турында» 2020 елның 18 мартындагы 48-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә керде.

Шуңа бәйле рәвештә закон проекты белән «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын, анда «Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең эшчәнлеген камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 6 апрелендәге 76-ФЗ номерлы Федераль закон урынына «Россия Федерациясе субъектларында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр турында» 2020 елның 18 мартындагы 48-ФЗ номерлы Федераль законны күрсәтеп, актуальләштерү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнары актларын үз көчләрен югалткан дип тану, туктатып тору, үзгәртү яисә кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.